КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 7 сентябрь г.Казань № 802

«Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектының «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә адреслы ярдәм күрсәтү» федераль проекты кысаларында Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген тотрыклы үстерүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны Татарстан Республикасында тормышка ашыру чаралары турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проекты нәтиҗәләренә ирешү өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 26 апрелендәге 510 номерлы карары нигезендә һәм «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә адреслы ярдәм күрсәтү» федераль проекты нигезендә «Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген тотрыклы үстерүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектының «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә адреслы ярдәм күрсәтү» федераль проекты кысаларында Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген тотрыклы үстерүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны Татарстан Республикасында тормышка ашыруга бәйле чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында федераль бюджеттан Татарстан

Республикасы бюджетына башка бюджетара трансферт рәвешендә бирелә торган акчаны тоту тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгын «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проекты составына керә торган «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә адреслы ярдәм күрсәтү» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә адреслы ярдәм күрсәтү» төбәк проектын Татарстан Республикасында тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансферт бирү өлешендә Россия Федерациясенең Икътисадый үсеш министрлыгы белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы итеп билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының сәнәгать бүлегенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 7 сентябрь, 802 нче
карары белән расланды

«Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектының «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә адреслы ярдәм күрсәтү» федераль проекты кысаларында Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген тотрыклы үстерүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны Татарстан Республикасында тормышка ашыруга бәйле чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансферт рәвешендә бирелә торган акчаны тоту
тәртибе

1. Бу Тәртип «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектының «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә адреслы ярдәм күрсәтү» федераль проекты кысаларында Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген тотрыклы үстерүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны Татарстан Республикасында тормышка ашыруга бәйле чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансферт (алга таба – башка бюджетара трансферт) рәвешендә бирелә торган акчаны тоту тәртибен билгели.

2. Бу Тәртип максатларында түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

Хезмәт җитештерүчәнлеге өлкәсендә төбәк компетенцияләр үзәге (алга таба – Төбәк компетенцияләр үзәге) – «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Энергия саклау технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесе (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 21 октябрь, 802 нче карары нигезендә).

Процесслар фабрикасы – чынбарлыктагы җитештерү һәм ярдәмче процессларны имитацияләү ярдәме белән «сакчыл җитештерү» принципларына һәм инструментларына гамәли укытуны тәэмин итә торган мәйданчык.

Консультант – үзенең алга киткән җитештерү системасы булган компания йә «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектында катнашучы предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү программаларын тормышка ашыруга эксперт (консультация, методологик) ярдәмен түләүле нигездә күрсәтергә әзер булган консалтинг компаниясе.

«Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектында катнашучы предприятиеләр (катнашучы предприятие) – «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә адреслы ярдәм күрсәтү» төбәк проектына кертелгән һәм «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проекты чараларын тормышка ашырганда Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы (алга таба – Министрлык) белән үзара хезмәттәшлек итү турында килешү төзегән предприятие.

3. Федераль бюджеттан башка бюджетара трансферт Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы өчен Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә (алга таба – Казначылык) ачылган шәхси счетка керә.

4. Башка бюджетара трансфертны тоту бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

5. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы, бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм башка бюджетара трансфертны финанслауның иң чик күләмнәре турындагы мәгълүматны Казначылыктан алганнан соң, җиде эш көне эчендә агымдагы финанс елына башка бюджетара трансфертны финанслауның иң чик күләмнәрен Министрлыкка җиткерә.

6. Министрлык, агымдагы финанс елына башка бюджетара трансфертны финанслауның иң чик күләмнәре турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасының Финанс министрлыгыннан алганнан соң, агымдагы финанс елына башка бюджетара трансфертны финанслауның иң чик күләмнәрен җиде эш көне эчендә «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә адреслы ярдәм күрсәтү» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә адреслы ярдәм күрсәтү» төбәк проекты чараларын тормышка ашыручы Төбәк компетенцияләр үзәгенә Министрлык тарафыннан билгеләнгән агымдагы финанс елына бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә ирештерә.

7. Бу Тәртипнең 6 нчы пунктында күрсәтелгән акча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектының түбәндәге нәтиҗәләренә ирешү өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләрен (алга таба – Кагыйдәләр) раслау турында» 2019 елның 26 апрелендәге 510 нчы карары нигезендә чараларны тормышка ашыру өчен Төбәк компетенцияләр үзәгенә җибәрелә:

а) Төбәк компетенцияләр үзәген оештыру һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү;

б) «процесслар фабрикасы»н булдыру һәм аның эшләвен тәэмин итү;

в) катнашучы предприятиеләрдә эшләү өчен консультантлар җәлеп итү.

8. Бу Тәртипнең 6 нчы пунктында күрсәтелгән акча түбәндәге максатларда бирелә:

а) оештыру техникасы, портатив компьютерлар, периферияләр, махсус киемнәр, җиһаз һәм инвентарь сатып алу; эш хакы фондын формалаштыру;

хезмәткәрләрне укыту; Төбәк компетенцияләр үзәге эшчәнлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән башка максатларда;

б) бина урынын арендалау һәм карап тоту; җайланмалар, шул исәптән уку-укыту җайланмалары һәм оештыру техникасы, махсус киемнәр, җиһаз һәм инвентарь сатып алу, методик яктан тәэмин итү, «процесслар фабрикасы»н булдыру һәм аның эшләвен тәэмин итү өчен тренерларның эш хакы фондын формалаштыру;

в) катнашучы предприятиеләрдә консультантларның хезмәте өчен түләү.

9. Төбәк компетенцияләр үзәге үзенә билгеләнгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә һәм, үз счетына бу Тәртипнең 6 нчы пунктында күрсәтелгән акча керүгә карап, дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр башкаруны, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы законнар таләпләре нигезендә дәүләт контрактлары (шартнамәләр) төзелгән оешмаларның счетына акча күчерүне гамәлгә ашыра.

10. Төбәк компетенцияләр үзәге ай саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 5еннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары (аларны финанслау максатларында башка бюджетара трансферт бирелә) турындагы хисапны, башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турындагы хисапны «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектының «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә адреслы ярдәм күрсәтү» федераль проекты кысаларында Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген тотрыклы үстерүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны 2019 елда Татарстан Республикасында тормышка ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Энергия саклау технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә башка бюджетара трансфертлар акчасы хисабыннан субсидия бирү турындагы килешү белән күздә тотылган формалар буенча Министрлыкка кертә.

Министрлыкка кертелә торган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык Төбәк компетенцияләр үзәгенә йөкләнә.

11. Министрлык, Төбәк компетенцияләр үзәге башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү өчен җавап бирә.

12. Министрлык хисапларны билгеләнгән вакытларда Федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъекты бюджетына максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансферт бирү турындагы 2019 елның 16 июнендәге 139-17-2019-007 номерлы килешү (алга таба – Килешү) белән күздә тотылган формалар буенча Россия Федерациясенең Икътисадый үсеш министрлыгына кертә.

13. Бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына керә торган башка бюджетара трансферттан максатчан файдаланмау бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка тарта.

14. Хисап елыннан соң килә торган финанс елының 1 гыйнварына карата башка бюджетара трансфертның файдаланылмаган өлеше федераль бюджетка Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә кире

кайтарылырга тиеш.

15. Әгәр башка бюджетара трансферт бирү елының 31 декабре хәленә карата һәм алдагы ике елда Килешүдә күрсәтелгән башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү буенча йөкләмәләр бозылган һәм башка бюджетара трансферт бирү елыннан соң килә торган елда һәм алдагы ике елда Килешүдә күрсәтелгән башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү турында хисаплылык кертүнең беренче көненә кадәр әлеге бозулар бетерелмәгән булса, башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килә торган елның 1 июненә кадәр Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджетка кире кайтарылырга тиешле акча күләме Кагыйдәләрнең 10 нчы пункты нигезендә формула буенча исәпләп чыгарыла.

16. Бу Тәртип нигезендә бирелгән акчаны максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүендә тоту органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.